**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет**
**Пестречинского**
**муниципального района**
422770, с. Пестрецы, ул. Советская, 18

**Татарстан Республикасы**
**Питрәч муниципаль**
**районы**
**башкарма комитеты**
422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 18

тел. +7 (84367) 3-02-02 факс: (84367) 3-02-01E-mail: pitriash@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«02» апрель, 2021 ел № 218

2021 елның 2 кварталына салым салынырга тиешле гражданнар керемнең һәм мөлкәт хакының чик күрсәткечләрен раслау турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 14 статьясы, «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-РТ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, һәм һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең чик күрсәткечләрен һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм күрсәтелгән законга кушымтада бәян ителгән салым салынырга тиешле мөлкәтнең хакын билгеләү методикасы белән «Россия Федерациясе буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының һәм Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урынының гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар хакын билгеләү методикасын раслау турында» 2013 елның 05 мартындагы 66/ДС номерлы Госстрой боерыгы белән расланган Методиканы файдаланып, «Бәяләр диапазонын билгеләү турында» 2021 елның 12 февралендәге 48 номерлы «Татарстан Республикасы Бәяләүчеләр берлеге» коммерцияле булмаган партнерлыгының хатына таянып, Россия Федерациясе субъектлары буенча торак

урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының 2021 елның 2 кварталына уртача базар хакы күрсәткечләре турында» Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2021 елның 26 февралендәге 94/пр боерыгына таянып, Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. Гражданнарны аз керемле дип тану турында карар кабул итү өчен түбәндәге чик күрсәткечләрне билгеләргә:

1.1. Гаилә әгъзалары (ялгыз яшәүче граждан) милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакы ставкасы:

1.1.1. Ялгыз яшәүче граждан өчен - 1 601 490 сум

1.1.2. Ике кешелек гаилә өчен - 2 038 260 сум

1.1.3. Өч кешелек гаилә өчен - 2 620 620 сум

1.1.4. Дүрт кешелек гаилә өчен - 3 494 160 сум

1.1.5. Биш кешелек гаилә өчен - 4 367 700 сум

1.1.6. Алты кешелек гаилә өчен - 5 241 240 сум

1.1.7. Җиде кешелек гаилә өчен - 6 114 780 сум

1.2. Гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык керем күләме:

1.2.1. Ялгыз яшәүче граждан өчен - 17 486 сум

1.2.2. Ике кешелек гаилә өчен - 11 127 сум

1.2.3. Өч кешелек гаилә өчен - 9 538 сум

2. Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлегенә әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 бүлекләрендә күрсәтелгән чик күрсәткечләрдән файдалануны социаль наем шартнамәләре буенча муниципаль торак фондын исәпкә кую һәм аларга торак урыннары бирү максатларында аз керемле дип тану өчен файдаланырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Питрәч муниципаль районы
башкарма комитеты җитәкчесе А.В. Хәбибуллин